Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Югары Пәнәче авыл җирлегенең Бура-Киртә торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**18 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Бура-Киртә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Бура-Киртә торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025 елда үзара салымны 600 сумм күләмендә билгеләргә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зиратта югары үсә торган агачларны һәм куакларны кисү);
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (1 янгын гидранты урнаштыру);
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (төркем күмү урынында истәлек билгесе урнаштыру).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы** ________________ **М. Х. Туктаров**